РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«16» февраль 2026 ел № 30

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының типовой индикаторларын раслау турында» 2025 елның 20 маендагы 301/пр номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чирмешән районы прокурорының 2026 елның 02 февралендәге 02-08-01/50-р номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 27 гыйнварындагы 90 номерлы, 2023 елның 24 июлендәге 191 номерлы, 2023 елның 12 декабрендәге 215 номерлы, 2024 елның 28 мартындагы 236 номерлы, 2024 елның 12 ноябрендәге 271 номерлы, 2025 елның 13

мартындагы 300 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 9 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, региональ операторлар, төзүчеләр, күпфатирлы йортка турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашыручы күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре белән күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту һәм (яисә) ремонтлау эшләрен башкару буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре төзелгән затлар, күпфатирлы йортта мондый урын милекчеләренә торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр»

1.2. Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Әлеге карарның 1.1 пунктында билгеләнгән Нигезләмәнең гамәлдә булуы 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://cheremshan.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2026 елның
16 февралендәге 30 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
территориясендә муниципаль
торак контроле турында
2021 елның 30 сентябрендәге
63 номерлы нигезләмәгә
2 нче кушымта

**МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК КОНТРОЛЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ БОЗУ КУРКЫНЫЧЫ ИНДИКАТОРЛАРЫ**

1. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органның Россия Федерациясе арбитраж суды тарафыннан күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга тиешле төрдәге коммуналь хезмәтләр күрсәтүне һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар сатып алуны тәэмин итү максатларында, энергия белән тәэмин итү (сату-алу, электр энергиясе (егәрлек), җылылык белән тәэмин итү һәм (яисә) кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү, газ белән тәмин итү (шул исәптән көнкүреш газын баллоннарда китерү) шартнамәсе (шартнамәләре) буенча, планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү һәм аның төрен сайлау турында карар кабул ителгән көнгә кадәр унике ай эчендә төзелгән каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә гомуми суммасы өч йөз мең сумнан артып киткән шартнамә (шартнамәләр) буенча бурычларны түләтү турында дәгъва гаризасы (дәгъва гаризалары) кабул ителүе хакында белешмәләр булу.

2. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан расланган куллану нормативыннан чыгып, җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү исәпләү турында белешмәләрнең рәттән өч хисап чорыннан артыграк булуы.